# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан  Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

12.11.2025 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 март 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы,  Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт авылында  2025 елның 12 ноябрендә 17.00 сәг. узган гражданнар җыенында “2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан,  махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, кертергә  һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?” дигән сорау буенча   йомгаклау беркетмәсе төзелде:
1) традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймаларны кору, төзекләндерү (зиратны киртәләү өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру);
2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторы өчен чапкыч сатып алу)»?
Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 231 граждан кертелде, тавыш бирүдә катнашучылар саны 119 кеше.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен   119 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0.

1. Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2.  “2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт торак пунктында яшәү урыны буенча

теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?" дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

1) традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймаларны кору, төзекләндерү (зиратны киртәләү өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру);

2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторы өчен чапкыч сатып алу)»?

3. Карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Монашево авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru "Монашево авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары реестрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Иосифов